**Минем педагогик осталыгым.**

( Эссе )

***Олы Әтнә урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сабирҗанова Светлана Илдус кызы***

Укытучы һөнәрен мәңгелек һөнәр дип атыйлар. Кеше дөньяда яши башлаганнан бирле һәрвакыт укыту, өйрәтү, үз тәҗрибәсен яшь буынга күчерү һәм тормыш тәҗрибәсен үзләштерү ихтыяҗы кичергән.

Яшьләрнең остазлары, кагыйдә буларак, белемлерәк һәм хөрмәтлерәк кешеләр булалар. Башкарган эшнең әһәмиятлелеге, абруйлы укытучыларның дәрәҗәсе бу һөнәргә ихтирамлы мөнәсәбәт тудырган.

Мин укытучы һөнәренә кечкенәдән гашыйк.Укытучылар гаиләсендә тууым, кечкенәдән мәктәп бусагасын таптавым, билгеле, эзсез калмады. Мин укытучы һөнәрен сайладым. Тормыш сукмаклары мине мәктәп белән гомерлеккә бәйләде. Хезмәтемнән зур һөнәри канәгатьләнү алам. Укучыларымда милли үзаң, горурлык, патриотизм хисләре тәрбияләргә тырышам. Һәр дәресемне башка фәннәр, тормыш вакыйгалары һәм әхлак темалары белән тыгыз бәйләп алып барам. Укучыларымда туган җиребездәй назлы, җырдай моңлы, бөек Тукай һәм батыр Җәлил теле булган ана теленә мәхәббәт тәрбиялим.

Бүгенге көндә татар теле укытучысыннан күп хезмәт сорала. Ул укучыларына белем бирү белән беррәттән, аның туган теленең дә, нәкъ башка телләр кебек үк, кирәкле һәм затлы тел булуын төшендерергә тиеш. Моның өчен, әлбәттә, иң беренче үзеңнең дә шушы хакыйкатькә чын күңелдән ышануың мөһим.

Ана теле укытучысы гамәлләре аша халыкның холкы, характеры, акылы, әхлагы, рухы чагыла. Укучыга үз мөгаллимендә мондый кыйммәтләрне күрү бик мөһим. Әгәр укытучыда ватандашларының иң матур сыйфатлары бар икән, моны укучылар сизә һәм аларда үзеннән-үзе милли горурлык хисе уяна.

Мин, татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, укучыларымда туган телебезгә мәхәббәт, аның белән горурлану хисләре тәрбияләргә тырышам. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, күренекле, зыялы шәхесләрен онытмаска өйрәтәм.

Һәр елны туган тел дәресләрен мин туган тел турындагы әңгәмәдән, татар теленең бөеклеге, халкыбыз тарихын сөйләүдән башлап җибәрәм. Укучыларыма туган тел турында ятлаган шигырьләрен сөйләтәм, күңелләрендә сакланган мәкаль-әйтемнәрен әйттерәм. Өйгә эш итеп тә туган тел турында яңа мәкаль-әйтемнәр өйрәнеп килергә кушам. Мондый башлам миңа укучыларымның туган телгә булган мөнәсәбәтен ачыкларга зур мөмкинлек, ел буена җитәрлек көч-дәрман бирә.

2015-2016 нчы уку елыннан “ Яңа федераль белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерү” дигән методик тема өстендә эшлим. Һәр дәресне, яңа технологияләр кулланып, заманча үткәрергә тырышам. Бүгенге көндә һәр укучыга иҗади якын килеп, аны шәхес итеп карап белем бирү һәм тәрбияләү аша гына укытучы уңышларга ирешә алачак. Мин дәресләрне М.Мәхмүтовның проблемалы укыту технологиясенә нигезләнеп үткәрәм. Дәрес башында, яки яңа теманы аңлатыр алдыннан, проблема куярга, укучылар белән аны бергәләп чишәргә, уйланырга, фикер йөртергә, алдан үзләштергән белемнәргә таянып, ачышлар ясарга мөмкинлек бирә ул. Шулай ук, дәресләрдә Ә.З. Рәхимов, А. Г. Яхин технологияләреннән дә файдаланам. Ә.З. Рәхимовның да татар теле дәресләрендә төркемләп эшләү ысулы көчле укучыларны гына эшләтү түгел, киресенчә, йомшак укучыларны баткаклыкта калдырмыйча, башкалар артыннан ияртеп алып бару өчен кулай. Әлегә тулысынча бу методология буенча эшләмәсәм дә, күп кенә дәресләремдә аерым элементларын теләп кулланам. Бигрәк тә йомгаклау һәм күзәтү дәресләрендә укучылар төркемендә проект эшләрен тикшерү зур нәтиҗәләр бирә. Мәсәлән, тел дәресләрендә укучыларымның китаптан әзер тестларны кулланмыйча, мөстәкыйль рәвештә үз тест вариантларын төзүләре, әдәбият дәресләрендә аерым бер чорга яисә темага карата чыгыш-презентацияләр әзерләве, фәнни-гамәли эзләнү эшләре укучыларыбызга район һәм республика күләмендәге конференцияләргә җиңел юл яра.

Ә дәресләрне компьютер технологиясен кулланып уздыруның өстенлекләре әйтеп бетергесез. Лексик материалның дөрес язылышын, транскрипциясен, сурәтен экранда бирергә мөмкин. Әдәби әсәрнең эчтәлеге буенча сурәтләр, өзекләр файдаланырга була. Экрандагы рәсем, схема, таблицалар ачык, төсле, һәр баланың игътибарын җәлеп итәрлек сыйфатлы була, шуңа күрә тема укучыларда зур кызыксыну уята. Яңа материалны үзләштерергә этәргеч бирә.

Язучылар биографиясен өйрәнү дә татар әдәбияты курсының бер өлеше булып тора. Язучының тормышы, иҗаты, халкы белән үзара мөнәсәбәте тикшерелә. Әдәбият дәресләрендә, укучыларны эзләнү эшенә тарту максатыннан, һәр әдип иҗаты буенча чыгышлар хәзерләргә бирәм. Шулай ук күп кенә язучыларның тормыш юлы, иҗаты турында укучыларым белән бергә презентацияләр эшләү – иҗадилыкка тагын бер юл. Мондый дәресләрне үткәргәндә кабинетта булган интерактив китаплар, дисклардан файдаланам. Кабинетымда дәресләрдә куллану өчен дидактик материаллар, күрсәтмә әсбаплар, фронталь һәм индивидуаль эш өчен төрле биремнәр тупланган карточкалар, тестлар, магнитофон язмалары, видеоязмалар тупланган. Алар системага салынып, картотекасы төзелгән.

Гомумән, «Интернет» челтәре буенча сәяхәт, компьютерда үз хезмәтеңне тудыру укучыларны бик мавыктыра. Бер караганда, уен кебек кенә тоелса да, укучы язучы иҗаты турында күпме мәгълүмат туплый. Дөрес, әсәрне инде компьютер аша тиз генә өйрәнеп булмый, аның өчен

бала кулына китап алырга тиеш. Укучыда китапларга мәхәббәт уяту максатында, күмәк һәм аерым сәнгатьле укулар, төрле иҗади ярышлар, укучылар конференцияләре үткәрәм. Бигрәк тә Әмирхан Еникинең “Без дә солдатлар идек”, Нур Әхмәдиевның “Аксак төлке”, Хәсән Сарьянның “Егет язмышы” китапларын укучыларым яратып укыды һәм әсәрләр буенча рәхәтләнеп фикер алыштылар.

Дәресләр үткәргәндә проект методы, компьютер технологияләреннән файдалану, уен – дәресләр үткәрү укучыларда татар теле һәм әдәбияты дәресләренә мәхәббәт уятуга ярдәм итә. Мавыктыргыч эш төрләрен, кызыклы биремнәрне урынлы куллану, укучыларның иҗади сәләтен, фикерләү дәрәҗәсен үстерергә, язма һәм телдән сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итә. Бу укучыларның республика һәм район күләмендә үткәрелгән чараларда актив катнашуында да чагыла.

Укытучы кулы белән киләчәк тормыш төзелә. Замана укытучысы бар нәрсәдән дә алда барырга, күп белергә, заманча техника белән дөрес һәм урынлы файдалана белергә тиеш, әлбәттә. Компьютер, проектор, электрон энциклопедияләр, видеотехника, мультимедия тактасы, интернет челтәре + эшкә юнәлтелгән укытучы = менә заманча дәрес бирүнең чаралары. Дәресләремә төзелгән слайдлар, видео һәм аудиоязмалар татар теле һәм әдәбияты дәресләремне тагын да тулырак, тагын да нәтиҗәлерәк итә. Һәр яңа мәгълүматымның күрсәтмәлелектә чагылдырылуы, бер яктан, вакытка экономия ясаса, икенче яктан, дәлилле һәм тирән эчтәлекле итәргә дә ярдәм итә. Дәрес азагында белемнәрен барлау өчен актив тест куллану да укучыларымны иҗади эшкә рухландыра һәм зур җаваплылыкка тарта.

Дәрестән тыш үткәрелгән чараларда да укучылар белән актив катнашабыз. Мәктәптә һәр язучының юбилейлары билгеләп үтелә, төрле очрашулар үткәрелә.

Сыйныф җитәкчесе буларак, укучыларымның бер-берсе белән дус, тату булуларына игътибар итәм. Укучыларда халкыбызның онытыла барган гореф-гадәтләрен, буыннан-буынга күчеп килгән гүзәл сыйфатларын тәрбияләүне максат итеп куям. Ата-аналарны физик һәм әхлакый яктан сәламәт балалар тәрбияләүдә бергәләп актив эшләргә җәлеп итәм.

Бер акыл иясе әйткән: берничә айдан уңыш алыйм дисәң – иген чәч, ун елдан җимеш ашыйм дисәң – агач утырт, гомерең буе кадер- хөрмәттә яшим, җир йөзендә якты эз калдырыйм дисәң – бала укыт! Язмыш безнең өлешкә соңгысын язган икән, үзебез сайлаган әлеге юлдан хөрмәткә һәм ихтирамга лаек булып кына атласак иде!